**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 8 июнендәге 1929 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1284 номерлы «Казан шәһәре территориясендә сезонлы тематик ярминкәләрне оештыру планын һәм урнаштыру схемасын раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 4 мартындагы 171 номерлы «Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләр оештыру һәм аларда товарлар сату (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү) тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәрендә ярминкәләр уздыру урыннарының үзгәрүенә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 27 апрелендәге 1284 номерлы «Казан шәһәре территориясендә сезонлы тематик ярминкәләрне оештыру планын раслау турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2020 елның 29 маендагы 1513 номерлы, 2020 елның 17 сентябрендәге 2621 номерлы, 2020 елның 25 сентябрендәге 2713 номерлы, 2020 елның 5 ноябрендәге 3170 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 3759 номерлы, 2021 елның 26 апрелендәге 1010 номерлы, 2021 елның 9 июнендәге 1442 номерлы, 2021 елның 2 сентябрендәге 2174 номерлы, 2021 елның 15 октябрендәге 2653 номерлы, 2021 елның 21 октябрендәге 2743 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 3374 номерлы, 2022 елның 25 маендагы 1513 номерлы, 2022 елның 1 ноябрендәге 3750 номерлы, 2023 елның 1 мартындагы 609 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 2883 номерлы, 2024 елның 1 июлендәге 2751 номерлы, 2025 елның 3 июлендәге 2072 номерлы, 2025 елның 26 августындагы 2738 номерлы, 2025 елның

24 сентябрендәге 3099 номерлы карарлары белән кергән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 номерлы кушымтада:

1.1.1. 94 юлда «04.07.2025 – 13.07.2025» көннәрен «кирәк булган саен» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 95 юлда «43» санын «45» санына алмаштырырга;

1.1.3. 54, 55, 57, 62, 72 юлларын түбәндәге редакциядә бирергә:

| № т/б | Ярминкәнең төре | Ярминкәнең тибы | Уздыру вакыты | Уздыру урыны | Урыннар саны | Мәйданы, квадрат метрларда | Ярминкәне оештыручы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «54 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Җиңү проспекты, 146а (Совет районы) | 3 кә кадәр | 45 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3) |
| 55 | Тематик | Махсуслаштырылган (авыл хуҗалыгы) | Ихтыяҗ туган саен | Ш.Усманов урамы, 1 (Мәскәү районы) | 50 гә кадәр | 4200 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3)» |
| «57 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Ленинград урамы, 22 (Авиатөзелеш районы) | 10 га кадәр | 100 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3)» |
| «62 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Ю.Фучик урамы, 64 (Идел буе районы) | 40 ка кадәр | 1200 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3)» |
| «72 | Тематик | Универсаль | Көн саен | Комиссар Габишев урамы, 36 (Идел буе районы) | 3 кә кадәр | 45 | Казан шәһәре Башкарма комитеты (Казан шәһәре, Кремль урамы, 3)» |

1.2. 2 номерлы кушымтада:

1.2.1. Чехов урамы, 3/7 (Вахитов районы) буенча урнашкан объектны урнаштыру схемасын әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендәге редакциядә бирергә;

1.2.2.Ф.Әмирхан урамы, 26, мәйданы 45 кв.м (Яңа Савин районы), Академик Глушко урамы, 28, мәйданы 45 кв.м (Совет районы), Беломорск урамы, 6, мәйданы 500 кв.м (Авиатөзелеш районы), Ленинград урамы, 27, мәйданы 3600 кв.м (Авиатөзелеш районы), Побежимов урамы, 28, мәйданы 45 кв.м (Авиатөзелеш районы), П.Баранов һәм Ударная урамнары киселешендә, мәйданы 45 кв.м (Авиатөзелеш районы), Тэц урамы, 4, мәйданы 45 кв.м (Авиатөзелеш районы), Чехов урамы, 2, мәйданы 1315 кв.м. (Вахитов районы), Р.Зорге урамы, 66, 1 корпус, мәйданы 994 кв.м (Идел буе районы) булган объектларны урнаштыру схемаларын төшереп калдырырга;

1.2.3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә Ш.Усманов урамы, 1 (Мәскәү районы), Җиңү проспекты, 146а (Совет районы), Ленинград урамы, 22 (Авиатөзелеш районы), Ю.Фучик урамы, 64 (Идел буе районы), Комиссар Габишев урамы, 36 (Идел буе районы) объектларын урнаштыру схемаларын өстәргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  8 июнендәге
1929 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Чехов урамы, 3/7 йорт адресы буенча сезонлы тематик ярминкәләр урнаштыру схемасы**





Чехов урамы, 3/7 йорт, мәйданы – 45 кв.м.


______________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның  8 июнендәге
1929 номерлы  карарына
2 номерлы кушымта


**Кайбер сезонлы тематик ярминкәләрне Казан шәһәре территориясендә урнаштыру схемасы**





Ш.Усманов урамы, 1 йорт, мәйданы – 4200 кв.м.





Җиңү проспекты, 146а йорт, мәйданы – 45 кв.м.




Ленинград урамы, 22 йорт, мәйданы – 100 кв.м.




Ю.Фучик урамы, 64 йорт, мәйданы – 1200 кв.м.




Комиссар Габишев урамы, 36 йорт, мәйданы – 45 кв.м.